Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенә кергән Иске Үзи авыл авылында халык җыены нәтиҗәләре турындагы

КАРАР

2019 елның 19 ноябре № 1

06.10.2003 елда кабул ителгән № 131нче номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 28.07.2004 ел, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 2019 елның 5 ноябрендәге 105 номерлы карары белән 2019 елның 18 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Иске Үзи авылында узган, "Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм студентлардан тыш, 2020 елда бер тапкыр бирелә торган үзара салым акчасын 500 сум итеп түләүгә килешәсезме?» дигән сорау куелган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены протоколы төзелде. Җыеп алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелә:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген башкару;

- Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге урамнарны кышкы тәртиптә тоту;

- Иске Үзи авылының Гагарин, Ленин, Киров, Чапай, Горький, Яшьләр урамнарын ремонтлау (грунтны күтәрү, ком һәм вак таш салу); Чернышевский, Пушкин, Шоссе урамнарын ремонтлау;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Иске Үзи авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

- җирле халыкның массакүләм ял итү урыны өчен кирәкле товарлар сатып алу һәм коймалар урнаштыру;

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;

- Гагарин, Пушкин урамнарындагы сулыкларны чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛЫП КАЛДЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә 472 граждан, җыенда катнашучылар саны 242 кеше.
Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
«Риза» позициясе өчен 242 граждан тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
«Тыелып тордылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен чын дип игълан итәргә.

"Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм студентлардан тыш, 2020 елда бер тапкыр бирелә торган үзара салым акчасын 500 сум итеп түләүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча жыеп алынган акчаны

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген башкару;

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге урамнарны кышкы тәртиптә тоту;

- Иске Үзи авылының Гагарин, Ленин, Киров, Чапай, Горький, Яшьләр урамнарын ремонтлау (грунтны күтәрү, ком һәм вак таш салу);
Чернышевский, Пушкин, Шоссе урамнарын ремонтлау;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Иске Үзи авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

- җирле халыкның массакүләм ял итү урыны өчен кирәкле товарлар сатып алу һәм коймалар урнаштыру.

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру.

- Гагарин, Пушкин урамнарындагы сулыкларны чистартуга сарыф итәргә дигән карарны кабул итәргә.

4. Әлеге карарны Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының http://aksubaevo.tatar.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
5. Бу карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы башлыгы Н. В. Айдова